| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.04.2017 Казан шәһәре № под-678/17

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 22 статьясы, «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнвары 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы Положение нигезендә, мәгариф һәм фән өлкәсендә эшләүче хезмәткрләрне, шулай ук мәгариф һәм фән өлкәсен камилләштерүдә актив катнашкан башка хезмәткәрләрне кызыксындыру, мотивацияләү максатыннан б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе ;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хаты;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәте

2. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгының ведомство бүләкләре турында Положениене расларга

3. Кадрлар сәясәте бүлеге (Б.Алексеева):

бүләкләү документларын кабул итү, бүләкләү өчен материаллар әзерләү, ведомство бүләкләрен рәсмиләштерү һәм тапшыру, аларның исәбен алып бару эшен оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г. Ф. Гатиятуллина) ел саен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы сметасында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре бланкларын әзерләүне финанслау чыгымнарын күз алдында тотарга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Татарстан Республикасы Премьер-
министры урынбасары Э.Н.Фаттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
19.04.2017 № под-678/17
боерыгы белән

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
ведомство бүләкләре турында
ПОЛОЖЕНИЕ

## I. Гомуми положениеләр

1.1.Әлеге Положение Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләренә (алга таба – министрлыкның ведомство бүләкләре), тәкъдим итү һәм бүләкләү тәртибен, ведомство бүләкләре тасвирламасын билгели.

1.2.Ведомство бүләкләре әлеге Положениеда күрсәтелгән затларның казанышларын иҗтимагый тану һәм бүләкләү формасы булып тора.

1.3.Ведомство бүләкләре мәгариф, фәнни, фәнни-техник эшчәнлек, тәрбия, балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек, белем бирү оешмалары укучыларын социаль яклау , яшьләр сәясәте, министрлык карамагындагы башка өлкәләрдәге казанышлар һәм күпьеллык намуслы хезмәт өчен бирелә.

1.4.«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән (алга таба - күкрәк билгесе), мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары, өстәмә һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар, девиант тәртипле укучылар өчен махсус укыту оешмалары, мәктәпара уку комбинатлары, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы сәламәтләндерү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре, тәрбиячеләре һәм башка хезмәткәрләре бүләкләнә:

фән һәм мәдәниятнең заманча казанышлары яктылыгында белем бирү һәм тәрбия процессларын оештыруда һәм камилләштерүдә, белем һәм тәрбия бирүнең

бердәмлеген тәэмин итүдә, шәхеснең интеллектуаль, мәдәни һәм әхлакый үсешен формалаштыруда зур уңышларга ия;

укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрнең гамәли әзерлеген, аларның иҗади активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерүдәге уңышлар;

уку әдәбиятын, уку әсбапларын һәм җиһазларын эшләүдә һәм практикага кертүдә уңышлар;

дәресләр үткәргәндә, белемнәрне һәм технологияләрне тикшерү процессында , укучылар һәм тәрбияләнүчеләрнең шәхесен үстерүне , аларны өйрәтүне индивидуализацияләүне тәэмин итә торган яңа формалар һәм ысуллар кертү һәм куллану.

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән фәнни-тикшеренү оешмалары, фәнни-методик үзәкләр, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәсе органнары хезмәткәрләре, шулай ук мәгариф оешмаларына югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә һәм матди-техник базасын үстерүдә гамәли ярдәм күрсәткән оешмалар, мәгълүмати-методик эшне оештыруда уңышларга ирешкән министрлыклар һәм ведомстволар хезмәткәрләре бүләкләнә ала.

1.5.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән (алга таба - Мактау грамотасы) яшь буынны укытуда һәм тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы оешмалары хезмәткәрләре түбәндәге казанышлары өчен бүләкләнә;

мәгариф системасында күпьеллык намуслы хезмәт; белем бирү процессын оештыру һәм камилләштерүдә уңышлар;

Татарстан Республикасы мәгариф системасын үстерүгә керткән өлеш; белгечләрне һәм фәнни-методик кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү буенча зур һәм нәтиҗәле эш;

белем бирү һәм тәрбия процессларына яңа технологияләр, укыту формалары һәм методларын кертү, белем һәм тәрбиянең бердәмлеген тәэмин итү, шәхеснең интеллектуаль, мәдәни һәм әхлакый үсешен формалаштыру;

дәреслекләр һәм укыту-методик әдәбият, күрсәтмә әсбаплар һәм җиһазлар булдыруга керткән өлеш;

мәгарифнең актуаль проблемалары буенча фәнни тикшеренүләрне үстерү, төбәк, федераль, халыкара мәгариф һәм фәнни-техник программаларда һәм проектлардагы казанышлар, фән, техника, мәгариф һәм мәдәниятнең өстенлекле юнәлешләре буенча вузара программаларны гамәлгә ашыру;

студентлар, аспирантлар, укучылар һәм тәрбияләнүчеләрне гамәли әзерләүдә, аларның иҗади активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерүдә ирешкән уңышлар.

Мактау грамотасы белән укудагы уңышлары өчен оешмаларның укучылары (тәрбияләнүчеләре, студентлары, аспирантлары) бүләкләнә.

Мактау грамотасы белән мәгариф системасын үстерүгә ярдәм итүче һәм мәгариф органнары һәм оешмалары тарафыннан үткәрелә торган чараларда актив катнашучы затлар бүләкләнә ала.

1.6.Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хаты белән Татарстан Республикасы мәгариф системасында күп еллар намуслы хезмәт куйган, Татарстан Республикасының белем бирү ситемасын устерүгә шәхси өлеш керткән, Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары хезмәткәрләре (алга таба - хезмәткәрләр) бүләкләнә.

Рәхмәт хаты белән, Татарстан Республикасы мәгариф системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш керткән өчен, республика предприятиеләре, коллективлары, оешмалары, предприятие хезмәткәрләре бүләкләнә ала.

1.7.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәте (алга таба - Рәхмәте) оешма хезмәткәрләренә, коллективларына, оешмаларга, министрлык кушуы буенча оештырыла торган аерым конкурслар, олимпиадалар, күргәзмәләр һ.б үткәрү белән бәйле конкрет чаралар өчен; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры яисә аның урынбасарларының күрсәтмәләрен югары дәрәҗәдә үтәүләре өчен игълан ителә. Рәхмәт югарыда күрсәтелгән чараларны оештыруга һәм үткәрүгә ярдәм иткәннәре өчен, фән һәм мәгариф системасын үстерүдә, камилләштерүдә актив катнашкан оешмалар һәм шәхесләргә дә белдерелергә мөмкин

Рәхмәттә хезмәткәрнең әлеге чараны үткәрүдә турыдан-туры өлеше яки конкрет катнашуы чагылдырыла, аның уңышлары һәм хезмәттәге казанышлары яктыртыла.

1.8.Ведомство бүләкләре белән бүләкләнүгә кандидатлар шул ук вакытта түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1.8.1. Эш стажы булу:

әлеге Положениенең 1.3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек өлкәсендә кимендә 15 ел, шул исәптән бүләкләүгә тәкъдим иткән оешмада 5 ел - «Мәгарифтәге казанышлары өчен " күкрәк билгесе белән бүләкләү өчен

әлеге Положениенең 1.3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек өлкәсендә кимендә 10 ел, шул исәптән бүләкләүгә тәкъдим итүче оешмада 3 ел - Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен;

бүләкләүгә тәкъдим иткән оешмада кимендә 1 ел - Министрлыкның Рәхмәт хаты белән бүләкләү, министрлык Рәхмәтен белдерү өчен.

башка юридик затка хокук һәм вазыйфалар тапшырып, оешма ябылган, таратылган яисә үзгәртеп корылган очракта, кандидатның эш (хезмәт) стажына таләпләргә туры килүен билгеләгәндә, өзлексез хезмәт стажы саклана һәм санала.

1.8.2. Тиешле эшчәнлек өлкәсендә һөнәри казанышлары булу (нәтиҗәле һәм намуслы хезмәт эшчәнлеге (хезмәт) өчен бүләкләү турында мәгълүматлар).

1.8.3. Федераль законда билгеләнгән тәртиптә хөкемгә тартылмаган булу, яисә, хөкем карарының срогы узган булу.

1.8.4. Бетерелмәгән дисциплинар җәза булмау.

## II. Ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү тәртибе

2.1.Ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы үтенечнамә кузгату турындагы карар, коллектив тарафыннан, бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның төп эш (хезмәт итү) урыны буенча кабул ителә һәм оешманың коллегиаль органы ( коллегия, гыйльми, фәнни, фәнни-техник, педагогик советы, коллективның гомуми җыелышы) тарафыннан карала. Ведомство бүләге төре әлеге Положение нигезендә,

бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның ирешкән кзанышларының дәрәҗәсен һәм характерын исәпкә алып билгеләнә.

2.2.Ведомство бүләкләре белән бүләкләү түбәндәге эзлеклелектә башкарыла.

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән элек Мактау грамотасы белән бүләкләнгән хезмәткәрләр бүләкләнә. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә стажы 30 елдан артык булган хезмәткәрләр искәрмә булып тора.

Мактау грамотасы белән элек Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән хезмәткәрләр бүләкләнә.

Министрлыкның Рәхмәт хаты һәм Министрлыкның Рәхмәте белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән очракта югарыда күрсәтелгән эзлеклелек кулланылмый.

2.3.Бүләкләүгә тәкъдим ителгән затлар саны:

гомуми штаттагы хезмәткәрләр саны 100 кешедән ким булган оешмадан бер елга бер кешедән артмаска тиеш;

гомуми штаттагы хезмәткәрләр саны 100 кешедән артыграк булган оешмадан, һәр 100 кешегә ел саен бер кешедән дә артмаска тиеш.

2.4.Бүләкләүгә берничә кандидатураны тәкъдим иткәндә үтенечнамә гомуми исемлек белән рәсмиләштерелә.

2.5.Үтенечнамә әлеге Положениенең кушымтасында тәкъдим ителгән бүләкләү кәгазендә (алга таба - бүләкләү кәгазе) рәсмиләштерелә. Бүләкләү кәгазендә кандидатның конкрет казанышлары, оешма (орган) яки Министрлык эшчәнлегенә керткән шәхси өлеше турында мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш.

Бүләкләү кәгазенә түбәндәгеләр теркәлә: оешмада (органда) эшләүче штаттагы хезмәткәрләренең гомуми саны турында белешмә; хезмәткәрне бүләкләүгә тәкъдим итүче оешманың коллегиаль органы карары.

2.6.Ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнәр кертә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры яисә аның урынбасарлары;

башка дәүләт оешмалары җитәкчеләре яки аларның урынбасарлары;

Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары;

әлеге Положениеның 1.3 пунктында күрсәтелгән өлкәдә идарә итүне гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре;

фәнни оешмалар, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм башка оешмалар җитәкчеләре.

2.7.Министрлык карамагындагы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы , фәнни һәм башка оешмалар үз хезмәткәрләрен, шул исәптән филиал хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы документларны турыдан-туры Министрлыкка юллыйлар.

2.8.Министрлык карамагындагы белем бирү, фәнни һәм башка оешмаларның филиаллары бүләкләү турында документларны баш оешмага юллыйлар, кандидат әлеге Положениеның таләпләренә туры килгән очракта, баш оешма аларны Министрлыкка җибәрә.

2.9.Дәүләт хакимиятенең башка федераль органнары карамагында булган, белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы, фәнни һәм башка оешмалар, кандидатны бүләкләү турында документларны әлеге ведомство карамагындагы дәүләт хакимияте органына җибәрә. Ведомство, кандидат элеге Положениенең таләпләренә туры килгән очракта, үз үтенечнамәсе белән аларны Министрлыкка җибәрә

2.10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге карамагында булган белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмалар, фәнни һәм башка оешмалар тиешле муниципаль берәмлек Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә (алга таба - мәгариф бүлеге) бүләкләү турында документлар җибәрә

Мәгариф бүлеге, тәкъдим ителгән документларны коллегиаль карый һәм, кандидат әлеге Положениеның таләпләренә туры килсә, министрлыкка коллегиаль орган карары белән үтенечнамә җибәрә, анда бүләкләүгә тәкъдим ителгән хезмәткәрнең исеме, фамилиясе, атасының исеме (булганда), билгеләнгән өлкәдә һәм оешмада аның (аларның) вазыйфасы һәм эш стажы күрсәтелә.

Күкрәк билгесе белән, Министрлыкныж Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән очракта, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге

Башкарма комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләү датасы күрсәтелә. Тәкъдим итүдә шулай ук министрлык карамагындагы тиешле өлкәдә муниципаль берәмлектә хезмәткәрләр саны турында мәгълүматлар күрсәтелә.

2.11.Шәхси белем бирү оешмалары, дәүләтнеке булмаган фәнни яки башка оешмалар, бүләкләү турында документларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгына карап тикшерүгә җибәрә., кандидат әлеге Положение таләпләренә туры килгән очракта, бүләкләү турындагы документлар Министрлыкка җибәрелә.

2.12. Министрлык хезмәткәрләрен бүләкләү турында документлар Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләре яисә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасарлары тарафыннан кертелә.

2.13.Тапшырылган документлар нигезендә Министрлык 90 көн эчендә кандидатны ведомство бүләге белән бүләкләү яки кандидатны ведомство бүләге белән бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры яисә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары тарафыннан бүләкләүгә тәкъдим ителгән затларны бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул ителсә, документлар әлеге Положение таләпләрен бозып тәкъдим ителсә, бүләкләү турында үтенечнамә, сәбәпләрен күрсәтеп, керү датасыннан 90 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

## III. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе

3.1.Ведомство бүләге белән бүләкләү Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

3.2.Ведомство бүләге белән бүләкләү тантаналы шартларда, кагыйдә буларак, бүләкләнүчегә эш (хезмәт) урыны буенча, бүләкләү турында боерык чыкканнан соң 6 айдан да соңга калмыйча башкарыла.

3.3.Күкрәк билгеләре һәм аларга таныклыклар, мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары, ведомство бүләкләрен тапшыру Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры яисә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры

урынбасарлары тарафыннан оештырылмаса, хезмәткәрне бүләккә тәкъдим иткән оешма вәкилләренә тапшырыла.

3.4.Яңа казанышлар өчен чираттагы ведомство бүләге алдагы бүләкләүдән соң ике елдан да иртәрәк бирелми.

3.5.Ведомство бүләге белән бүләкләнученең хезмәт кенәгәсенә бүләкләү турында язу кертелә.

3.6.Ведомство бүләкләренең бер үк төре белән кабат бүләкләү каралмый.

3.7.Ведомство бүләкләрен яки аның таныклыгын югалткан очракта, Министрлык, бүләкләү фактын раслаучы белешмә бирә. Ведомство бүләкләре дубликатлары бирелми.

3.8.Ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән затларның исәбен министрлык алып бара.

## IV. Ведомство бүләкләре тасвирламасы

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе сары металлның җиңел сплавыннан әзерләнә, 26 мм диаметрлы түгәрәк дискка ия.

Күкрәк билгесенең алгы ягында ачык китап, аның янында лавр тәлгәшенең рельеф сурәте, түгрәк буйлап сулдан һәм уң яктан «Мәгарифтәге казанышлары өчен» һәм «За заслуги в образовании»дигән язулар урнаштырылган.

Ушка һәм бөҗра ярдәмендә Медаль, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы рәвешендә эшләнгән, 26 х 16 мм зурлыгында турыпочмаклы колодка белән тоташтырыла.

Икенче якта билгене кием-салымга беркетү өчен булавка бар.

Таныклыкның киңлеге: 222 мм, биеклеге 148мм. Икегә бөкләнгән хәлдә 109х148 мм; эчке киселешнең размеры: 99х142мм.

Таныклыкның тышы караңгы-яшел төстәге, тыгызлыгы145 гр/кв. дан ким һәм 150 гр/кв. дан артык булмаган тышлык материалдан әзерләнә.

Таныклыкның алгы өлешенең бизәлеше: кайнар алым белән металланган «алтын» фольга белән төшерелгән бизәк. Түгәрәкләнгән почмаклар, тоташкан урында кисемтә белән.

Таныклыкның эчке өлешен бизәкләү Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиль элементларын төзү һәм куллану визуаль стандартлары паспорты турында» 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы рәсми һәм эшлекле стиль элементларын төзүнең һәм куллануның визуаль стандартлары паспорты нигезендә төгәл гамма нигезендә башкарыла.

Мактау грамоталары тыгызлыгы 145 г/кв.м дан ким, 175 г/кв.м дан: артык булмаган кәгазьдән эшләнә. Мактау грамотасының размерлары: киңлеге - 420 мм, биеклеге - 297 мм., икегә бөкләнгән килеш - 210х297 мм.

Мактау грамоталарын бизәкләү Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиленең визуаль стандартлары паспортына туры килгән төсләр гаммасында башкарыла.

Рәхмәт хаты тыгызлыгы 145 г/кв.м дан ким, 175 г/кв.м дан: артык булмаган кәгазьдән эшләнә. Размеры: киңлеге - 420 мм, биеклеге - 297 мм.

Рәхмәт хатларын бизәкләү Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиленең визуаль стандартлары паспортына туры килгән килгән төсләр гаммасында башкарыла.

Министрлыкның Рәхмәте (благодарность) тыгызлыгы 145 г/кв.м дан ким, 175 г/кв.м дан артык булмаган кәгазьдән эшләнә. Министрлыкның Рәхмәтен бизәкләү Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиленең визуаль стандартлары паспортына туры килгән төгәл төсләрдә башкарыла.

Тәкъдим ителә торган үрнәк

Кушымта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомство бүләкләре турындагы Положениегә
“____” __________2017 №________

БҮЛӘКЛӘҮ БИТЕ

________________________________________________________
бүләк исеме

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (паспорт буенча)

(рус телендә)________________________________________________

(татар телендә)______________________________________________

2. Туган көне ___________________________________________
(көне, ай, ел)

3. Милләте_________________

4. Җенесе_____________________________________________

5. Белеме (уку йорты исеме, факультет,тәмамлау елы)__________________

________________________________________________________
(уку йортының тулы исеме, тәмамлау елы)

6. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, квалификация категориясе_________

_________________________________________________________

7. Эш урыны, вазыйфасы (оешма, район, өлкә исеме)
_______________________________________________________________
(рус телендә)
_______________________________________________________________
(татар телендә)

8. Мәгариф системасында эш стажы ________________________________

9. Әлеге коллективта эш стажы _____________________________________

10. Нинди Дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, бүләкләү датасы_________________________________________________________

11 бүләкләүнең башка төрләре, бүләкләү датасы (тармак бүләкләре)____________________________________________________

12. Адресы: ____________________________________________________

13. Буләккә тәкъдим ителгән хезмәткәрнең конкрет казанышларын күрсәтеп Характеристика

14. Кандидатура ____________________________________________________________
(мәгариф оешмасы советы, фәнни оешма, Гыйльми советы, педагогика Советы, коллегия,

________________________________________________________________________________
фикер алышу датасы, № беркетмә)

____________________________________________________________тәкъдим ителде

М. П. оешма җитәкчесе ___________________ *Ф. И. О.*
(имза)

15. Мәгариф идарәсе (бүлеге) бәяләмәсе

Мәгариф идарәсе (бүлеге) җитәкчесе ___________________________*Ф. И. О*